| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>КОШКИ-НОВОТИМБАЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ТЕТЮШСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ТӘТЕШ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КОШКИ-НОВОТИМБАЕВО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

тел. (84373) 52-6-31, факс 52-6-31

**КАРАР**

**14 ноябрь 2019 ел** **№ 1**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Кошки-Новотимбаево авыл җирлегенең Максимовка торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсенә нигезләнеп, **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 27 ноябрендә 9.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш районы Максимовка авылы Рыжов ур. 4 йорт адесы буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбаево авыл җирлегенең Максимовка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Кошки-Новотимбаево авыл җирлегенең Максимовка торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Максимовка авылы зират территориясен койма белән әйләндереп алу?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге башлыгы С.В. Гаврилов**